СОВЕТ
БОЛЬШЕЦИЛЬНИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗУР ЧЫНЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

с.Большая Цильна

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2020 нче елның 02 июне № 63/4

**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Зур Чынлы авыл җирлеге территориясендә ачык тыңлаулар оештыру һәм үткәрү турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

2017 елның 29 декабрендә кабул ителгән 455-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» гы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Зур Чынлы авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Зур Чынлы авыл җирлеге Советының 18.04.2012 ел, № 14/2 карары ( 12.10.2018 ел 38/3 номерлы редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Зур Чынлы авыл җирлеге территориясендә ачык тыңлаулар оештыру һәм үткәрү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында:
**2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**
«2.1. Ачык тыңлаулар халык, авыл җирлеге Советы, авыл җирлеге башлыгы, авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе инициативасы белән үткәрелә.»;

**4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**
«**4.1. Халык яки авыл җирлеге Советы** инициативасы белән үткәрелә торган ачык тыңлаулар авыл җирлеге Советы, ә авыл җирлеге башлыгы яки авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе инициативасы белән контракт

нигезендә үз вәкаләтләрен башкаручы авыл җирлеге башлыгы тарафыннан билгеләнә.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Зур Чынлы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Зур Чынлы авыл җирлеге башлыгы: Ф.Җ.Фатхуллов